РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Нижнекамский муниципальный район
СОВЕТ
муниципального образования
«пгт Камские Поляны»

423564, «пгт Камские Поляны»,
д.4/04,
тел: (8555) 35-00-01, факс: 35-00-04

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
«Кама Аланы штп»
муниципаль берәмлеге
СОВЕТЫ

423564, «Кама Аланы штп», 4/04
йорт,
тел: (8555) 35-00-01, факс: 35-00-04

Решение
Карар

22.06.2023 ел № 12

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
«Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 91, 92, 93 статьялары нигезендә, гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен карап чыкканнан соң, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 17 июлендәге 26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://kamalan.ru бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Р.Р.Сәлахетдинов

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 22 июнендәге 12 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы
«Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. «Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр» 6 статьясының 3 пунктын:

- түбәндәге эчтәлектәге 23.1 һәм 23.2 пунктлар белән тулыландырырга:

«23.1) урманчылыкларны, җирлек җирләрендә урнашкан, алар составында төзелә торган участок урманчылыкларын булдыру, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү, шулай ук җирлек җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләү һәм раслауны гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү;

23.2) җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман төзелеше буенча чараларны гамәлгә ашыру;

- 38 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«38) федераль закон нигезендә торак пункт ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрнең үтәлешен тәэмин итү.».

2. «Җирле референдум» 12 статьясындагы 7 пунктының икенче абзацында:

- «Җирлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «Җирле референдум әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләре белән алыштырырга (алга таба – сайлау комиссиясе)»;

3. «Муниципаль сайлаулар» 13 статьясындагы 3 пунктының өченче абзацында:

- «Җирлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан (алга таба – сайлау комиссиясе)» сүзләре белән алыштырырга;

4. «Җирлек Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү» 14 статьясында түбәндәге эчтәлек буенча бәян итәргә:

5 нче пунктта:

- «Җирлекнең сайлау комиссиясен» сүзләрен «Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясен (алга таба – сайлау комиссиясе)» сүзләре белән алыштырырга;

- 8, 12 пунктларда:

- «Җирлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «Сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләре белән алыштырырга.

5. «Яңа сайланган җирлек Советы эшен оештыру» 32 статьясының 1 пунктында:

- «Җирлек сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан (алга таба – сайлау комиссиясе)» сүзләренә алыштырырга.

6. «Җирлек Советы компетенциясе» 31 статьясының 15 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

7. «Җирлек башлыгын сайлау тәртибе» 42 статьясындагы 1 пунктының 2 абзацында:

- «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

8. «Башкарма комитет вәкаләтләре» 49 статьясының 3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

- урманчылыкларны, җирлек җирләрендә урнашкан, алар составында төзелә торган участок урманчылыкларын булдыру, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү, шулай ук җирлек җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләү һәм раслауны гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү;

- җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман төзелеше буенча чараларны гамәлгә ашыру;

- федераль закон нигезендә җирлек ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрнең үтәлешен тәэмин итү.

9. «Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 54 статьясының 2 пунктындагы 2 пунктчасында:

- «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

10. VII бүлек. «Сайлау комиссиясе» үз көчен югалткан дип танырга.

11. «Җирлек Советы депутаты, башка вазыйфаи затлар эшчәнлегенең социаль һәм башка гарантияләре» 63 статьясының 3 пунктында:

- «һәм җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга.

12. «Җирлектә бюджет процессы» 84 статьясындагы 7 пунктының 2 абзацында:

- «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.